# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

“30” ноябрь 2022 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 30 ноябрендә «Сез 2023 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизациялэнгэн гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бахтияр авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Бахтияр авылы урамнарына ремонт һәм каплау (вак таш сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- урам яктырту хезмәте (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) һәм яктырткычлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **139** (йөз утыз тугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 84 (сиксән дүрт) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 84 (сиксән дүрт) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2023 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизациялэнгэн гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган:

- Бахтияр авылы территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачларны кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Бахтияр авылы урамнарына ремонт һәм каплау (вак таш сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- урам яктырту хезмәте (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) һәм яктырткычлар сатып алу белән килешәсезме", - дигән сорауга җавап буларак, җыен карарын кабул ителгән дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Бахтияр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Филатова Ф.Ф.